| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **Нагорная ул., 99а с.Утяшки, 422514** | **Нагорная ур., 99а Өтәшкә ав, 422514** |

# КАРАР

2023 елның «22» мае № 15

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатыннан, зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитеты **карар итә:**

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында, һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәүләре» 2011 елның 28 апрелендәге 16 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылсын.

2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2011 елның 28 апрелендәге 16 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2012 елның 23 мартындагы 9 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылсын «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү турында».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең мәгълүмат

стендларында түбәндәге адреслар буенча: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Өтәшкә авыл
җирлеге башлыгы — А.А. Клопов